ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 октябрь 2025ел №8161

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2020 елның 20 маендагы 2336 номерлы Карарына 2 нче кушымтаның 2 пунктына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә күп балалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибе турында» 2024 елның 17 октябрендәге 893 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2020 елның 20 маендагы 2336 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 10 маендагы 3754 номерлы Карары редакциясендә) 2 нче кушымтаның 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күп балалы гаиләнең барлык әгъзалары да Россия Федерациясе гражданнары булу шарты белән күп балалы гаиләләр өчен ата-аналар түләве 50 процентка киметелә, шул ук вакытта 18 яшькә кадәрге һәм (яки) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән 23 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы (шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган балалары, үги уллары һәм үги кызлары, шулай ук белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада белем алу сәбәпле ата-аналарыннан аерым яшәүче күрсәтелгән категориядәге балалары) булган гаиләләр күп балалы дип санала.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«Ата-аналар түләвен киметү ел саен документлар пакеты: ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы, балаларның туу турында таныклыкларының күчермәләре, 23 яшькә кадәрге балаларның уку урыныннан белешмәләр, күп балалы гаилә таныклыгы тапшырылу датасыннан гамәлгә ашырыла.

Әгәр ата-аналар түләвен киметү өчен нигезләр туктатылган булса, ата-аналар (законлы вәкилләр) нигезләр туктатылган көннән башлап өч эш көне эчендә бу хакта мәктәпкәчә белем бирү оешмасына хәбәр итәргә тиеш.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов